ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31 01 2023 г. № 70

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 628 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 3 декабрендәге 383-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 628 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

1 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт белән тулыландырырга:

«1.6. Муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Алдан (проактив) режимда муниципаль хезмәтләр, гариза бирүченең әлеге муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда күрсәтү турында соратуны алдан бирү шартларында һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә чаралар башкарганнан соң, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләр) (http:// www.gosuslugi.ru/) техник мөмкинлекне гамәлгә ашыру аша күрсәтелә»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә башкарма-боеру органы исеме

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Орган).»;

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы - документларны Органга тапшырганнан соң 45 көннән дә соңга калмыйча.

Документларны күпфункцияле үзәк аша тапшырган очракта, килештерү турында карар кабул итү яки килештерүдән баш тарту вакыты күпфункцияле үзәк тарафыннан мондый документларны Органга тапшырган көннән исәпләнә.»;

2.8.2 пунктчасында:

3 һәм 5 абзацларда «урынны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру» сүзләре алдыннан «күпфатирлы йортта» сүзләрен өстәргә;

6-8 нче абзацларны төшереп калдырырга;

2.10. пунктында «оешмалар тарафыннан бирелә торган» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтләр бирелгән экспертлар тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

3 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 3.0 пункты белән тулыландырырга:

«3.0. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә хезмәтләр күрсәтү тәртибен, шул исәптән уртак билгеләр белән берләшкән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренә карата аларны алу өчен мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, 2.13 пункты белән һәм әлеге бүлек белән билгеләнгән.»;

карарга 2 нче кушымтада:

1 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт белән тулыландырырга:

«1.6. Муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Алдан (проактив) режимда муниципаль хезмәтләр, гариза бирүченең әлеге муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда күрсәтү турында соратуны алдан бирү шартларында һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә чаралар башкарганнан соң, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләр) (http:// www.gosuslugi.ru/) техник мөмкинлекне гамәлгә ашыру аша күрсәтелә»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә башкар-ма-боеру органы исеме

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Орган).»;

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы - документларны Органга тапшырганнан соң 45 көннән дә соңга калмыйча.

Документларны күпфункцияле үзәк аша тапшырган очракта, килештерү турында карар кабул итү яки килештерүдән баш тарту вакыты күпфункцияле үзәк тарафыннан мондый документларны Органга тапшырган көннән исәпләнә.»;

2.10. пунктында «оешмалар тарафыннан бирелә торган» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтләр бирелгән экспертлар тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

3 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 3.0 пункты белән тулыландырырга:

«3.0. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә хезмәтләр күрсәтү тәртибен, шул исәптән уртак билгеләр белән берләшкән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренә карата аларны алу өчен мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, 2.13 пункты белән һәм әлеге бүлек белән билгеләнгән.»;

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов